❒ Ә сез беләсезме?

ХАЖ - ОЛУГ ФАРЫЗ ГЫЙБАДӘТЛӘРНЕҢ БИШЕНЧЕСЕ

Фәнүз ХӘБИБУЛЛИН



Мәдинә яки Джиддадан Мәккәгә кадәр юл гаять катлаулы булган. Ямбога килгән хаҗилар Мәдинәгә кадәр - 3 көн, аннан Мәдинәдән Мәккәгә кадәр 10 көн дөядә барганнар. Джиддага килүчеләр дөядә 2 тәүлектә яки ишәккә атланып 18 сәгатьтә Мәккәгә барып җиткәннәр. Юлның бу өлеше куркыныч булган, чөнки бәдәвиләр кәрванга еш һөҗүм иткәннәр, юлчыларны талаганнар. Русия мөселманнары төрек солтаны ел саен зур бүләкләр белән Мәккә җитәкчесенә җибәргән "солтан кәрванына" иярергә тырышканнар. Бәдәвиләр бу кәрванга һөҗүм итмәгән, чөнки аны гаскәр саклаган.

Урыс телен начар белү, хәләл ризык белән начар тәэмин ителү, поезд вагоннарының һәм пароходларның мөселманнар өчен уңайсызлыгы, юлда төрле ялганчы-каракларның сагалап торуы, бәдәвиләрнең һөҗүме ата-бабаларыбызның хаҗ сәфәрен шактый авырайта. Ләкин алар бу изге сәфәрдән баш тартмый. Хаҗ - авыр, мәшәкатьле, ләкин әҗер-савабы күп булган бер гыйбадәт.

Шуны да билгеләп үтәргә кирәк, Русия мөселманнары хаҗ сәфәреннән гарәп мәдәнияте һәм дөньяга карашын туган илләренә алып кайтканнар. Поезд һәм пароходлар барлыкка килгәнче ата-бабаларыбыз хаҗга җәяүләп, яки атка, дөягә атланып барганнар. Алар сәфәргә чыгардан алда гасырлар дәвамында мөселманнар гыйлем алган билгеле шәһәрләр аша үтә торган юл сайлаганнар. Алар анда туктап мәдрәсәләрдә гыйлем эстәгәннәр. Урта Азия: Бохара, Сәмәрканд һәм Хива яки Истанбул, Сүрия һәм Мисыр аша хаҗга барганнар. Гарәп-фарсы телләре һәм грамматикасы, Ислам дине нигезләре буенча алган гыйлемне алар кайткач якташларына укытканнар.

Октябрь революциясеннән соң үткәрелгән дингә каршы сәясәт нәтиҗәсендә 30нчы елларда мөселман руханиларын кысу, эзәрлекләү, гыйбадәтханәләрне ябу башлана, бик күп дин әһелләре кулга алына. Ул елларда СССРдан 20-30лап кеше генә хаҗ кыла.

Билгеле ишан Зәйнулла Рәсүлевның улы Габдрахман Рәсүлев мөселман дөньясында зур абруй казанган шәхес. Тугызынчы мөфтинең тәрҗемәи хәле 1947 елда Америка тикшеренүчесе Кэй тарафыннан "Who is Who in Religion" басмасына кертелә. 1945 елның 26 октябрендә мөфти Рәсүлев мөселманнарга хаҗ кылу мөмкинлеге бирелү турында хәбәр итә. Хөкүмәтнең рөхсәте белән 1945 елның декабрендә мөфти җитәкчелегендә 17 кешедән торган төркем хаҗга юллана. Алар арасында Уфаның Җәмигъ мәчете имамы Баймөхәммәт Тугызбаев та була. Хаҗдан кайткач, мөфти Габдрахман Рәсүлевны БАССР Халык Комиссарлары Советы рәисе Сабир Ваһапов кабул итә. Мөфти Тукай урамындагы җәмигъ мәчеттә мөселманнарны зәм-зәм суы белән сыйлый, хаҗ турында сөйли.

1847 елда СССРның 4 Диния нәзарәтеннән хаҗга 40 мөселман (аларның унысы Үзәк диния нәзарәтеннән) бара. Хаҗга бару 10 мең сум тора. Бу акчаның күп кенә өлешен мөселманнарга Диния нәзарәтләре бирә. СССР хөкүмәте Мәскәүдән Тегеранга очу өчен махсус самолет бүлә. Билет бәясе 3 мең сум тора. Тегераннан хаҗилар Мәккәгә юллана. Үзәк диния нәзарәтеннән хаҗга баручы 10 кеше арасында мөфти Габдрахман Рәсүлев, Уфа җәмигъ мәчете имамы Баймөхәммәт Тугызбаев, мулла Сафуан Даукаев була.

Хаҗга баруны ул чорда "капиталистик илгә туристик сәфәр оештыру" дип карыйлар, СССР хөкүмәте 1946 елда "Иранда катлаулы метеоролик хәл аркасында һәм һава элемтәсе булмау сәбәпле", 1948 елда "...кайбер гарәп илләрендә сәяси катлаулы хәл килеп туу нәтиҗәсендә" мөселманнарга хаҗ сәфәрен оештырмый. Югары мөселман руханилары хаҗны оештыруга ирешкән очракта да, барлык теләүчеләрне дә алып бара алмый. Хаҗ кылучылар санаулы гына була, кандидатлар катгый сайлап ала үтә, аларны иминлек хезмәте тикшерә. Моннан тыш, күпчелек мөселманнарның хаҗга барырлык акчасы да булмый. "Согуди-пресс" агентлыгы мәгълүматларына караганда, 1950 елга кадәр хаҗга килүчеләрнет саны 100 меңнән артмаган. 1955 елга аларның саны ике тапкыр арткан, ә 1972 елда 645 мең мөселман хаҗ кылган. 1983 елда беренче тапкыр хаҗиларның саны бер миллионнан артып киткән. Хаҗ кылучыларның саны артуы нәтиҗәсендә Ислам конференциясе оешмасы 1988 елда һәр ил өчен анда яшәүчеләр санына карап квоталар бирү турында резолюция кабул итә. 1992 елда Согуд Гарәбстаны чит мәмләкәтләрдән бер миллион мөселманны кабул итә, шулай ук илнең бер миллион гражданы хаҗ кыла.

Вөҗдан ирекe турында дәүләт сәясәте үзгәргәч, 1990 елда СССРдан 1500 мөселман хаҗ кыла. Төркемгә Баш мөфти Тәлгать хәзрәт Таҗетдин җитәкчелек итә. 1990-1993 елларда аларның саны үзгәрми диярлек. 2003 елдан Русиядә хаҗ кылырга теләүчеләр саны арта. 2003 елда - 4300, 2004 елда - 6200, 2005 - 9100, 2006 елда - 12500, 2007 елда - 18500, 2008 елда - 26500, ә 2010 елда 20 меңнән артык мөселман хаҗ кыла.

Өфөлә намаҙ ваҡыты

Мөхәррәм 2014 миләди йыл
1435 һижри йыл.

Мөхәррәм	Аҙна көндәре	Октябрь, Ноябрь	Иртәнге намаҙ	Ҡояш сыға	Өйлә нам.	Икен. нам.	Аҡшам.	Йәстү намаҙы
1	Шәмбе	25	7.36	9.06	14.30	17.23	18.53	20.23
2	Йәкшәмбе	26	7.38	9.08	14.30	17.21	18.51	20.21
3	Дүшәмбе	27	7.40	9.10	14.30	17.19	18.49	20.19
4	Шишәмбе	28	7.42	8.12	14.30	17.16	18.46	20.16
5	Шаршамбы	29	7.44	9.14	14.30	17.14	18.44	20.14
6	Кесе йома	30	7.46	9.16	14.30	17.12	18.42	20.12
7	Йома	31	7.48	9.18	14.30	17.10	18.40	20.10
8	Шәмбе	1	7.50	9.20	14.30	17.08	18.38	20.08
9	Йәкшәмбе	2	7.52	9.22	14.30	17.06	18.36	20.06
10	Дүшәмбе	3	7.54	9.24	14.30	17.06	18.34	20.04
11	Шишәмбе	4	7.56	9.26	14.30	17.02	18.32	20.02
12	Шаршамбы	5	7.58	9.28	14.30	17.00	18.30	20.00
13	Кесе йома	6	8.00	9.30	14.30	16.58	18.28	19.58
14	Йома	7	8.02	9.32	14.30	16.56	18.26	19.56
15	Шәмбе	8	8.04	9.34	14.30	16.54	18.24	19.54
16	Йәкшәмбе	9	8.06	9.36	14.30	16.52	18.22	19.52
17	Дүшәмбе	10	8.08	9.38	14.30	16.50	18.20	19.50
18	Шишәмбе	11	8.10	9.40	14.30	16.49	18.19	19.49
19	Шаршамбы	12	8.12	9.42	14.30	16.47	18.17	19.47
20	Кесе йома	13	8.14	9.44	14.30	16.45	18.15	19.45
21	Йома	14	8.16	9.46	14.30	16.43	18.13	19.43
22	Шәмбе	15	8.018	9.48	14.30	16.42	18.12	19.42
23	Йәкшәмбе	16	8.20	9.50	14.30	16.40	18.10	19.40
24	Дүшәмбе	17	8.22	9.52	14.30	16.39	18.09	19.39
25	Шишәмбе	18	8.24	9.54	14.30	16.37	18.07	19.37
26	Шаршамбы	19	8.26	9.56	14.30	16.36	18.06	19.36
27	Кесе йома	20	8.28	9.58	14.30	16.34	18.04	19.34
28	Йома	21	8.30	10.00	14.30	16.33	18.03	19.33
29	Шәмбе	22	8.32	10.02	14.30	16.31	18.01	19.31

ИМАНГА ЮЛ

Йосыф хәзрәт ДӘҮЛӘТШИН

ГЫЙБРӘТ

Һәрвакытта бер нәрсәгә вә бер хөкемгә хөҗҗәт (дәлил) торса, аның хаклыгы заһир (ачык) булса, мәрһәбеңә, иске мәэлүфеңә (ияләшкән нәрсә), ата-бабадан күргән гадәтеңә, остаз вә хәлфәләреңнән өйрәнгәнеңә хилаф (каршы) булса да, билгайни варраэси (шатланып) кабул итү тиештер. Дин бабында (өлкәсендә) хакның дәрәҗәсе ата-бабадан, остаз вә хәлфәдән, хәтта мәзһәб имамыннан бөектер. Һәркем дингә вә аның хөкеменә үзен вә фикерен вә мәзһәбен фида (корбан) итмәк ләзимдер. Бер бабта диннең хөкеме (Коръән вә сөннәтнең бәяны) анык беленсә, аңа һичкемнең сүзе вә һич имамның мәзһәбе каршы тора алмыйдыр, һәммәсе ул хөкемгә фида булырга тиештер.

Әгәр син диндә ачык исбатланган бер хөкемне: "Минем мәзһәбем алай түгел, яки минем остазларымнан, бабаларымнан өйрәнгәнем вә күргәнем алай түгел", дип каршы торсаң, диненңне тәклидеңә вә мәэлүфеңә фида иткән булырсың, олуг заләләткә (адашу) төшкән булырсың, ошбу югары аятьләргә мисдак булырсың (туры килерсең), Аллаһ сакласын!" Мулла Галимҗан әл-Баруди. "әд-Дин вәләдәб" журналы, № 13 1916 ел. 347-350 б.

* * *

Пәйгамбәребез әйтте: "Кем кое казып, ул коедан берәр җан иясе эчсә - җенме, кешеме, кошмы, Аллаһ ул эшенең кыямәт көнендә әҗерен бирер". ("Сахих" дәрәҗәсендәге хәдис).

Сәхабәләр пәйгамбәребезнең шушы һәм башка нәсихәтләре белән илһамланып, башкаларны сыйларга, су садәкасын бирергә тырыштылар. Пәйгамбәр вакытында өлкән буын өчен су табу бик авыр булган, шуңа күрә күп кенә яшьләр иртәләрен әби-бабайларның ишек төпләренә су калдырып китә торган булганнар.

Госманның биргән садәкаларын карасаң, исең-акылың китә. Мөселманнар Мәккәдән Мәдинәгә күчеп килгәч, Мәдинәнең табигать шартлары яхшы түгел иде. Күп коеларның сулары начар була. Шәһәрнең иң яхшы коелырының берсе булган Рум коесы бер кешенең шәхси милке була. Хуҗасы су сатып көнен күрә. Пәйгамбәребез аңа: "Бу коеңны җәннәттәге бер чишмә бәясенә сатмыйсыңмы?" - дип әйтә. Анысы: "Безнең шушы коебыздан башка һич керемебез юк шул", - дип акланырга тотына. Шулвакыт, Госман бу коены сатып алырга теләк белдерә һәм 35 мең дирһәм (көмеш тәңкә) биреп сатып та ала һәм пәйгамбәребездән: "Син миңа да ул кешегә вәгъдә иткәнне вәгъдә итәсеңме?" - дип сорый. Пәйгамбәребез: "Әйе", - ди Госман: "Мин бу коены Мәдинә халкына бүләк итәм", - дип әйтә. (Тирмизи риваяте).

Ислам тарихында су садәкасының иң зур үрнәге итеп Зөбәйдә коеларын санарга була. Зөбәйдә 762нчы елда туа. Аның бабасы - хәлиф Әбу Җәгъфар әл-Мансур, ире - Багдад әмире Харун әр-Рәшит була. 800нче елда ул хаҗ кылу нияте белән Багдадтан Мәккәгә юнәлә. Сәфәр вакытында юллар, эчәргә сулар булмау сәбәпле кешеләрнең газап чиккәннәрен күрә. Бу хәлләрдән тәэсирләнгән Зөбәйдә Багдадка кайткач, Мәккәгә су китерергә карар кыла һәм инженерларга бу проектны өйрәнергә куша. Алар бу эшнең бик кыйммәткә төшәсен хәбәр итәләр. Багдад белән Мәккә арасы 1400 чакрым. Ул заманнарда хәзерге торбалар, махсус техникалар булмый. Кулга кәйлә тотып казырга да казырга. Әле ул якларда бездәге кебек туфрагы йомшак түгел, таш катламы. Сулары да тирәндә ята. Зөбәйдә: "Тауны җимергәндә бер мәртәбә кәйлә белән сугу бер динарга төшсә дә эшлибез", - ди. Шулай итеп Мәккә белән Багдад арасында юл буйлап бик күп коелар казыйлар. Кешеләргә һәм малларга тукталу урыннары ясыйлар. Мәккәнең дә үз сулары хаҗиларга җитми, шуңа күрә ике чыганак табып, берсе 40 чакрым, икенчесе 30 чакрымга якын ике канал төзиләр. Гарәфә, Мөздәлифә, Мина җирләрендә дә сулар китерәләр. Ахыр чиктә Зөбәйдә коелары хәйрияче ханымга 5 мең 950 кг. чиста алтынга төшә. Бүген чиста алтынның бәясен белүчеләр бу проектның ничә сумга төшкәнен санап карый алалар.

Аллаһның рәхмәте белән, Аллаһ бу садәкага бәракәт бирә һәм узган гасыр башларында да ул коеларның файдасын күргәннәр. Зөбәйдә коелары 1200 ел халыкка хезмәт иткән, бүгенге көн байлык ияләренә дә үрнәк булып тора.

Су садәкасын вафат булган әти-әни өчен дә бирергә була. Имам Әхмәт риваять кыла: Сәгд ибн Губәдә пәйгамбәребез янына килеп: "Йә, Аллаһының илчесе, әнием вафат булды. Алар өчен садәка бирсәм буламы?" - дип сорый. Пәйгамбәребез: "Әйе", - ди. Ул янә: "Ә садәканың кайсысы яхшырак?" - ди. Пәйгамбәр: "Кешеләргә су эчертү", - дип әйтә (Хәсән хәдис).